РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ
«ГОРОД ЧИСТОПОЛЬ»
ЧИСТОПОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

**ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«ЧИСТАЙ ШӘҺӘРЕ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ

**ЧИСТАЙ
ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ**

***Решение*** ***Карар***

**2021 елның 28 апреле** **Чистай шәһәре** **№7/3**

«Җир салымын түләүнең ставкаларын, тәртибен һәм срокларын гамәлгә кертү турында» Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының 2016 елның 10 ноябрендәге 9/1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешенә үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 29 сентябрендәге 325-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставының 33 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Чистай шәһәр Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Җир салымын түләүнең ставкаларын гамәлгә кертү, аларны билгеләү турында» 2016 елның 10 ноябрендәге 9/1 номерлы карарына (Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының 2017 елның 07 ноябрендәге 16/3 номерлы, 2018 елның 27 июнендәге 26/3 номерлы, 2018 елның 23 ноябрендәге 29/2 номерлы, 2019 елның 07 октябрендәге 39/3 номерлы, 2019 елның 23 октябрендәге 40/2 номерлы карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. карар исемендә «һәм сроклары» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.2. 4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Салым түләүче-оешмалар җир кишәрлегенең кадастр бәясенең процент өлеше буенча тиешле салым ставкасының дүрттән бер өлеше күләмендә җир салымы буенча аванс түләүләрен түлиләр дип билгеләргә.».

2. Әлеге карарны «Чистай хәбәрләре» газетасында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru), шулай ук Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Порталда «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә (chistopol.tatar.ru) Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар җир салымы түләүгә һәм җир салымы буенча аванс түләүләре түләүгә бәйле рәвештә 2021 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә үз йогынтысын кертә дип билгеләргә.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән бер ай узгач кына үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе һәм депутат эшчәнлеге мәсьәләсе буенча даими депутат комиссиясенә О.В. Добронравовага йөкләргә.

Чистай муниципаль районының
Чистай шәһәре башлыгы Д.А. Иванов